СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 6-7 от « 10 » июня 2021 г.

Мамадыш муниципаль районы Советының 2017 елның 15 декабрендәге «Өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милек хокукларыннан тыш) азат булган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен Муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән муниципаль мөлкәтне (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибе турында» 6-20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында «Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Һөнәри керемгә салым» ("Үзмәшгуль гражданнар") махсус салым режимын кулланучы шәхси эшкуар булмаган физик затларга ярдәм итү максатында Мамадыш муниципаль район Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Советының 2017 елның 15 декабрендәге 6-20 карарының беренче кушымтасы белән расланган Өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милек хокукларыннан тыш) азат булган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен Муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән муниципаль мөлкәтне (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле 1.7 пунктны өстәргә:

«1.7. «Шулай ук исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендага алучылар «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы шәхси эшкуар булмаган физик затлар да була ала».

2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә секторына ун календарь көн эчендә әлеге карарны http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштырырга.

000042

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплы итеп Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары В.И. Никитинны билгеләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П. Иванов